КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 6 декабрь г.Казань № 1084

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 ел, 5 март, 178 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 ел, 5 март, 178 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 август, 559 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына ел саен, агымдагы елның 15 декабренә кадәр, чираттагы календарь елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ

анализ үткәрү графигы проектын раслау турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга җибәрергә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентында:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре эшчәнлегенә функциональ анализ үткәрүне оештыру өчен җаваплы үзәк булып тора. Функциональ анализ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ТР ИСТҮ ДБУ) тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының боерыгы белән ел саен раслана торган функциональ анализ үткәрү графигы нигезендә үткәрелә. Аерым очракларда функциональ анализ үткәрүгә бәйсез экспертларны җәлеп итү рөхсәт ителә.»;

2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы чаралар планын дәүләт хакимияте башкарма органнарына җибәргән көннән соң өч ай дәвамында аны үтәүне мониторинглауны һәм мониторинг нәтиҗәләрен алга таба Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумында карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүне гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.14 пункт өстәргә:

«2.14. Функциональ анализ нәтиҗәләре, шулай ук чаралар планын үтәү оештыру структурасын үзгәртү һәм штат санын арттыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшергәндә ике ел дәвамында (киләсе функциональ анализга кадәр) мәҗбүри исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин